СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

07.09.2018 с. Татарское Бурнашево 50-218

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Советы карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 17.08.2017 № 28-128 карары нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 1 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы карары проектын кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 2 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе 3 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” карары проекты буенча халык алдында

тыңлауларны 2018 елның 12 октябрендә 15.00 сәгатьтә Бурнаш авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, ТР, Югары Ослан районы, Татар Борнашы авылы, 62 нче йорт адресы буенча уздырырга.

4. Башкарма комитетка Бурнаш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

5. 2018 елның 11 сентябренә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С.В. Бурукин